**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№87** **22.02.2023ел**

**Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 апрелендәге 98 номерлы Поручик авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 декабрендәге 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 апрелендәге 98 номерлы Чыбыклы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә (Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 маендагы 99, 2018 елның 21 ноябрендәге 129, 2018 елның 06 декабрендәге 133, 2020 елның 22 сентябрендәге 5, 2021 елның 30 декабрендәге 46, 2022 елның 01.09. 72, 2022 елның 29.11. 75 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), 2.15 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3) вазыйфаи окладның 15 проценты күләмендә айлык акчалата түләү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә локаль актларны әлеге нигезләмә белән туры китерергә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Н. Гадершин**